КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 22 июль г.Казань № 705

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гомуми белем бирү оешмалары укучылары өчен сәнгать-анимация басмаларын бастырып чыгаруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү максатларында коммерциягә карамаган оешмаларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән тыш) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 30 июль, 665 нче карары белән расланган Гомуми белем бирү оешмалары укучылары өчен сәнгать-анимация басмаларын бастырып чыгаруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү максатларында коммерциягә карамаган оешмаларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән тыш) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гомуми белем бирү оешмалары укучылары өчен сәнгать-анимация басмаларын бастырып чыгаруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү максатларында коммерциягә карамаган оешмаларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән тыш) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 30 июль, 665 нче карары белән расланган Гомуми белем бирү оешмалары укучылары өчен

сәнгать-анимация басмаларын бастырып чыгаруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү максатларында коммерциягә карамаган оешмаларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән тыш) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия алучының, субсидияләр алучылар белән (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның үзләренә карата вәкаләтле орган тарафыннан субсидия бирү тәртибе һәм шартлары (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыруга, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә субсидия алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен тикшерүгә ризалыгы;»;

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Вәкаләтле орган, сайлап алу үткәрелә торган көнгә кадәр җиде календарь көннән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында һәм үзенең рәсми сайтында, түбәндәгеләрне күрсәтеп, сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштыра:

сайлап алуны үткәрү срокларын;

заявкалар бирелә башлау яки кабул итүне тәмамлау датасын (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән иртәрәк була алмый);

вәкаләтле органның исемен, урнашу урынын, почта адресын, электрон почта адресын;

бу Тәртипнең 19 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәсен;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган домен исемен, һәм (яки) челтәр адресын, һәм (яки) сайт битләре күрсәткечләрен;

бу Тәртипнең 9 пункты нигезендә оешмаларга карата таләпләрне һәм аларның әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен оешмалар тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлеген;

заявкалар бирү тәртибен һәм бу Тәртипнең 11 пункты нигезендә бирелә торган заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне;

заявкаларны кире алу тәртибен, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибен, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибен;

бу Тәртипнең 13 – 16 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү һәм бәяләү кагыйдәләрен;

коммерциягә карамаган оешмаларга сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләрен аңлату тәртибен, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасын;

сайлап алуда җиңүче тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүгә (алга таба – килешү) куелырга тиешле имза кую срогын;

сайлап алуда җиңүчене килешү төзүдән баш тарткан дип тану шартларын;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында һәм вәкаләтле органның рәсми сайтында, сайлап алуда җиңүче билгеләнгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңга калмыйча, сайлап алу нәтиҗәләрен урнаштыру датасын.»;

11 пунктның алтынчы абзацына «(9 пунктның өченче абзацында каралган таләпләргә документларның туры килүе өлешендә таләпнең гамәлдә булуы 2023 елның 1 гыйнварына кадәр туктатыла)» сүзләрен өстәргә;

18 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18. Килешү вәкаләтле орган тарафыннан субсидия бирү турында карар кабул ителгән, әмма бу Тәртипнең 17 пункты нигезендә сайлап алуда җиңүче турында мәгълүмат урнаштырылган датадан иртәрәк булмаган, эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан раслаган бертип форма буенча төзелә.

Килешүдә түбәндәгеләр карала:

субсидиянең максаты,

субсидиянең күләме;

финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнарның юнәлешләре;

субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләре;

субсидия күчерү тәртибе;

субсидия алучының бу Тәртипнең 25 пунктында билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап һәм субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү турында хисап бирү буенча йөкләмәсе;

субсидия алучының бу Тәртипнең 7 пунктында билгеләнгән субсидияләр бирү шартларын үтәү буенча йөкләмәсе;

килешүне вакытыннан алда туктату өчен нигезләр;

агымдагы финанс елында субсидия алучы тарафыннан субсидиянең хисап финанс елында файдаланылмый калган өлешен кире кайтару очраклары;

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп, вәкаләтле орган тарафыннан бу Тәртипнең 27 пунктында билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда әлеге акчага ихтыяҗ булу яки әлеге акчага ихтыяҗ булмаганда аларны кире кайтару турында карар кабул ителгәндә, финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлеше торган чыгымнарны гамәлгә ашыру мөмкинлеге каралган шарт;

субсидия алучының, субсидияләр алучылар белән (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның үзләренә карата вәкаләтле орган тарафыннан субсидия бирү тәртибе һәм шартлары

(шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыруга, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268[1] һәм 269[2] статьялары нигезендә субсидия алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен тикшерүгә ризалыгы;

субсидия алучы тарафыннан килешүдә билгеләнгән шартлар бозылган очракта, субсидия суммасын кире кайтару тәртибе;

субсидия алучы тарафыннан килешүне берьяклы тәртиптә өзүне тыю;

вәкаләтле орган тарафыннан килешүне берьяклы тәртиптә өзү өчен нигезләр;

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүнең бертип формасы кушымталарында бирелгән формалар буенча килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзү шарты һәм тәртибе һәм, вәкаләтле органга бу Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән, элек җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкинлеге булмауга китерә торган итеп киметкән очракта, килешүнең яңа шартларын килештерү турында яки яңа шартлар белән килешүгә ирешмәгәндә килешүне өзү турында шарт;

субсидия алучы тарафыннан бу Тәртип һәм төзелә торган килешү шартларын үтәү турындагы нигезләмәләр;

субсидия бирү шартларын һәм тәртибен бозган өчен җаваплылык;

Килешүдә вәкаләтле органның субсидия алучы тарафыннан өстәмә хисаплар бирү срокларын һәм формаларын билгеләү хокукы карала.»;

25 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«25. Субсидияләр алучылар квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 15 еннән дә соңга калмыйча, шулай ук субсидия бирелгән елдан соң килә торган елның 10 гыйнварыннан да соңга калмыйча, вәкаләтле органга Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләгән килешүләрнең бертип формаларына теркәлә торган формалар буенча субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү турында хисап, шулай ук финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап тапшыра.»;

26 пунктның өченче абзацында «нәтиҗәсенә» сүзен «нәтиҗәсе мәгънәсенә» сүзләренә алмаштырырга;

27 – 29 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«27. Хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлешләре субсидияләр алучылар тарафыннан субсидия бирелгән елдан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш (Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп, вәкаләтле орган тарафыннан әлеге акчага ихтыяҗ булу турында карар кабул ителгән очраклардан тыш).

Хисап финанс елында файдаланылмаган акчаны бу Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга җибәрүгә ихтыяҗ булган очракта, субсидия алучы, хисап елыннан соң килә торган елның 15 гыйнварыннан да соңга калмыйча, вәкаләтле органга мондый ихтыяҗны нигезләп мәгълүмат бирә.

Вәкаләтле орган, субсидия алучыдан бу пунктның икенче абзацында күрсәтелгән мәгълүматны алган көннән 10 календарь көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп, бюджет законнары нигезендә

субсидия алучының агымдагы финанс елында субсидиянең хисап финанс елында файдаланылмый калган өлешен җибәрүгә ихтыяҗы булу яки булмау турында карар кабул итә.

Вәкаләтле орган тарафыннан субсидия алучының агымдагы финанс елында субсидиянең хисап финанс елында файдаланылмый калган өлешен җибәрүгә ихтыяҗы булу турында карар кабул ителгән очракта, вәкаләтле орган һәм субсидия алучы арасында мондый карар кабул ителгән көннән календарь көннәрдә исәпләнелә торган өч көн эчендә өстәмә килешү төзелә.

28. Субсидияләр алучылар тарафыннан бу Тәртипнең 26 һәм 27 пунктларында күрсәтелгән субсидияләрне кире кайтару сроклары бозылганда, вәкаләтле орган субсидияләрне кире кайтару срогы чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнелә торган җиде көн эчендә әлеге акчаны законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына түләттерү буенча чаралар күрә.

29. Вәкаләтле орган субсидия алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә тикшерүне гамәлгә ашыра.

Дәүләт финанс контроле органы Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.»;

таблицага түбәндәге эчтәлекле 30 һәм 31 пунктлар өстәргә:

«30. Вәкаләтле орган, килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны төгәлләү фактын чагылдыра торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглауны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча гамәлгә ашыра.

31. Субсидиядән нәтиҗәле файдалануны, субсидия бирү шартларын һәм тәртибен үтәүне контрольдә тоту вәкаләтле орган тарафыннан гамәлгә ашырыла.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гомуми белем бирү оешмалары укучылары өчен сәнгать-анимация басмаларын бастырып чыгаруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү максатларында коммерциягә карамаган оешмаларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән тыш) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 30 июль, 665 нче карары белән расланган Гомуми белем бирү оешмалары укучылары өчен сәнгать-анимация басмаларын бастырып чыгаруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү максатларында коммерциягә карамаган оешмаларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән тыш) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенең 9 пунктындагы өченче абзацының гамәлдә булуын 2023 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

3. Бу карар (2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 1 пунктның илле өченче абзацыннан тыш) рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин